**МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.08.2024 № 298-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының аерым боерыкларын гамәлдән чыккан дип тану турында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларын федераль законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функциясен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Урман янгыннарын сүндерү үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учрждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә урманнарны авиапатрульләү өчен «очучы-күзәтүче» квалификациясе буенча белгечне укытуга бәйле булган чыгымнарны финанс яктан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 29 августындагы 451-осн номерлы;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функциясен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учрждениеләренә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә урман аударучылар арасында «Урман кисүче-2022» Россия чемпионатына Татарстан Республикасы делегациясен әзерләү һәм катнаштыруга бәйле чыгымнарны финанс яктан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 14 сентябрендәге 484-осн номерлы;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функциясен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учрждениеләренә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә хезмәткәрләрне бүләкләүгә бәйле чыгымнарны финанс яктан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 16 сентябрендәге 491-осн номерлы;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функциясен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Шәһәр яны өйрәнү-сынау урман хуҗалыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учрждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә төбәк әһәмиятендәге «Зәңгәр күлләр» комплекслы юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгын карап тотуга бәйле булган чыгымнарны финанс яктан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 19 сентябрендәге 493-осн номерлы;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функциясен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учрждениеләренә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә аерым категория хезмәткәрләрне бүләкләүгә бәйле чыгымнарны финанс яктан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 10 октябрендәге 517-осн номерлы;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функциясен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учрждениеләренә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә урман үсемлекләренең утырту материалын үстерүгә бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 5 декабрендәге 620-осн номерлы;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функциясен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учрждениеләренә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә аерым категория хезмәткәрләргә бер тапкыр кызыксындыру түләвен түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 21 декабрендәге 657-осн номерлы;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функциясен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учрждениеләренә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә агач әзерләү машиналарын, агач кисү җайланмаларын, транспорт чараларын сатып алу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 27 декабрендәге 665-осн номерлы;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функциясен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учрждениеләренә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә урман хуҗалыгы хезмәткәрләре өчен формалы кием тегүгә бәйле чыгымнарны финанс яктан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2023 елныың 30 гыйнварындагы 30-осн номерлы;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләренә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны, шулай ук дәүләт һәм муниципаль һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны туклану белән тәэмин итүгә субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2023 елның 14 февралендәге 60-осн номерлы;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функциясен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учрждениеләренә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә урта һөнәри белем бирүне үстерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2023 елның 16 февралендәге 67-осн номерлы.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А.Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Р.К.Гомәровка йөкләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров